**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ ________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2022-2023 еллардагы ягулык сезонын тәмамлау һәм 2023-2024 еллардагы көзге-кышкы чорда җылыту сезонына әзерләнү турында**

Тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы +8 градустан артып китү сәбәпле, «Гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 23 маендагы 307 номерлы карары нигезендә, торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрен, ягулык-энергетика комплексын һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны 2023-2024 елларның җылыту сезонына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларын җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга тәкъдим итәргә:

1.1. 2022-2023 еллардагы җылыту сезонын 2023 елның 26 апреленнән тәмамларга.

1.2. Көзге-кышкы чорда объектларны эшкә әзерләү чараларына ярашлы рәвештә, котельныйларда, үзәк җылылык пунктларында, тышкы челтәрләрдә һәм эчке инженерлык җылыту һәм кайнар су белән тәэмин итү системаларында ремонт һәм профилактика эшләренә керешергә.

2. 2023-2024 елларның көзге-кышкы чорына объектларны әзерләүне 2023 елның 15 сентябренә тәмамларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча:http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында:http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов